ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 3-05-44, факс: (84379) 3-05-44.

05.12.2024 ел № №2

На № от

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылыда гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 25 950 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:-Түбән Ослан торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча 2024 елның "05" декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 27 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 27 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 27 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендәге гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 25 950 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:- Түбән Ослан торак пункты чикләрендә

гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев